**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 6 августындагы 3263 нче номерлы карары**

**«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурс үткәрү турында**

Яшь педагогларның һөнәри компетенцияләрен арттыру максатыннан, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 3985 номерлы «Казан шәһәренең Муниципаль Бюджет һәм автоном учреждениеләренә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» карары нигезендә **карар бирәм**:

1. «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсен билгеләргә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурсында җиңүчеләргә түләүләренә 1 500 000,0 сум күләмендәге чыгымнарны «Мәгариф өлкәсендә гомумшәһәр чараларын үткәрү» 02 6 02 43600 максатчан статьясы, 0709 бүлек буенча 2024 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет язмасында каралган ассигнованиеләр чикләрендә тормышка ашырырга.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 6 августындагы
3263 номерлы карары белән
расланды

**«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурс үткәрү турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге нигезләмә «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурс (алга таба – Конкурс) яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә юнәлдерелгән субсидия алуга конкурсын үткәрүнең максатларын, бурычларын һәм үткәрү тәртибен, шулай ук субсидия бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

## II. Максатлары, бурычлары, терминнары

2.1. Әлеге Нигезләмәдә аны куллану максатларыннан түбәндәге терминнар кулланыла:

Конкурста катнашучылар – төп эш урыны «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре булган, узган елгы конкурста җиңүче булмаган, педагогик эшчәнлек стажы кимендә бер ел булган 35 яшькә кадәрге мәгариф оешмаларының яшь педагоглары;

субсидия алучылар – жюри тарафыннан Конкурста җиңүчеләр дип танылган һәм вәкаләтле орган – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән субсидия бирү турында килешү төзегән, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль

казна учреждениесе (алга таба – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе) карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре, яшь педагоглар.

2.2. Конкурсны уздыруның максаты - яшь педагогларның һөнәри компетенцияләренең нәтиҗәлелегеннән чыгып, субсидия алучыларны билгеләү.

2.3. Бурычлар:

- яшь педагогларның социаль статусын күтәрү;

- яшь педагогларның һөнәри үсеше, шәхес булып формалашуы, үз-үзен камилләштерүе һәм үз-үзен тормышка ашыруы өчен уңай шартлар тудыру;

- укытучы һөнәренең абруен күтәрү, педагог культурасын формалаштыру.

2.4. Субсидия бирүнең максаты – яшь педагогларны укыту һәм һөнәри яктан үстерү, һөнәри компетенцияләрне күтәрү.

2.5. Субсидиянең максатчан билгеләнеше бар һәм әлеге нигезләмәдә каралмаган максатка субсидия алучы аны файдалана алмый.

2.6. Субсидия бирү 2024 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет язмасы чикләрендә гамәлгә ашырыла.

## III. Катнашучылар категорияләре, гариза бирү тәртибе һәм формасы

3.1. Конкурс үткәрү турында игълан Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенең өстәмә битендә (https://obrazovanie.kzn.ru/) әлеге нигезләмәне раслаган көннән алып өч эш көне эчендә урнаштырыла. Белдерүдә түбәндәге мәҗбүри мәгълүматлар булырга тиеш:

- Конкурсны оештыручының исеме, аның урнашу урыны адресы, почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры һәм Конкурсны оештыру өчен җаваплы затның урнашу урыны адресы;

- документлар тапшыру вакыты, урыны һәм тәртибе;

- сайлап алуда катнашучылар гаризаларын бирә башлау һәм кабул итүне тәмамлау даталары;

- сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризаларны бирү тәртибе һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган гаризаларның формасына һәм эчтәлегенә таләпләр;

- Конкурсны уздыру турында мәгълүматны үз эченә алган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайтның исеме;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кайтарып алу тәртибе, сайлап алуда катнашучыларга гаризаларны кайтару өчен нигезләрне дә билгели торган сайлап алуда катнашучыларга гаризаларны кайтару тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның гаризаларына үзгәрешләр кертү тәртибе;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләре;

- сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турында хәбәрнамә нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, аңлатма бирүнең башлану һәм тәмамлану вакыты;

- сайлап алуда җиңүчеләр субсидия бирү турында килешүне имзаларга тиешле вакыт аралыгы;

- сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төземәгән дип тану шартлары;

- Конкурс нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру датасы.

3.2. Конкурс түбәндәге срокларда уздырыла:

- гаризалар кабул итү: 2024 елның 5 августыннан 1 сентябренә кадәр;

- гаризаларны карау һәм тапшырылган материалларга экспертиза ясау вакыты: 2024 елның 11 сентябреннән 25 сентябренә кадәр.

Конкурска нәтиҗә ясау жюри әгъзалары утырышында гаризаларны карау һәм тәкъдим ителгән материалларга экспертиза ясау тәмамланганнан соң, әмма 2024 елның 26 сентябреннән дә соңга калмыйча беркетмәгә имза салу юлы белән уздырыла.

3.3. Конкурстта катнашу өчен катнашучылар «Яшь педагогларны укытуга конкурс» тамгасын куеп, info@kazanobr.ru электрон почтасына *.zip яки *.rar форматындагы архивлаштырылган бер файл белән түбәндәге материалларны җибәрә:

- әлеге нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча гариза;

- әлеге нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча катнашучының портфолиосы;

- әлеге нигезләмәнең 3 номерлы кушымтасында бирелгән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

3.4. Гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар чынлыкта алынган көнне теркәлә. Гаризалар кабул итү срогы тәмамланганнан соң вәкаләтле

органга тапшырылган гариза теркәлми һәм Конкурста катнашуга кертелми.

3.5. Гаризалар кабул итү тәмамланган көннән алып 10 эш көне эчендә вәкаләтле орган бирелгән гаризаларны әлеге нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә тикшерә.

Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда гаризаны кире кагу турында карар кабул итә:

- Конкурста катнашучының әлеге нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;
- Конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге нигезләмә документларына карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);
- Конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

3.6. Гаризалары тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килми дип танылган Конкурста катнашучыларга бу хакта тикшерү тәмамланган көннән алып биш эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан электрон почта адресы аша хәбәр ителә.

3.7. Тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә дип танылган гаризалар тикшерү тәмамланган көннән алып өч эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан жюрига тапшырыла.

## IV. Конкурс жюрие

4.1. Кергән гаризаларны бәяләү өчен конкурс жюрисы (алга таба – жюри) төзелә, ул кимендә 5 әгъзадан тора. Жюри рәис, рәис урынбасары, секретарь, жюри әгъзаларыннан тора.

Жюриның персональ составы вәкаләтле орган боерыгы белән раслана һәм Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе өстәмә битендә (https://obrazovanie.kzn.ru/) бастырып чыгарыла.

Жюри утырышын уздыру өчен кворум жюри әгъзалары санының яртысыннан да ким булмаска тиеш.

Жюри карарлары утырышларда жюри әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта жюри утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Жюри рәисе жюри эшчәнлегенә җитәкчелек итә, аның карарын раслый. Жюри рәисе булмаганда, аның функцияләрен жюри рәисе урынбасары башкара.

Жюри секретаре жюри рәисе кушуы буенча жюри утырышын әзерләүне оештыру функцияләрен башкара.

Жюри әгъзасының мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул бу хакта жюри рәисенә хәбәр итә һәм шәхси кызыксынуы булган гаризаны бәяләүдә катнашмый.

4.2. Жюри:

- Конкурста катнашуга рөхсәт ителгән гаризаларны карап тикшерә;

- әлеге нигезләмәдә билгеләнгән бәяләү критерийлары нигезендә гаризаларны бәяли;

- Конкурста җиңүчеләрне билгели.

## V. Гаризаларны бәяләү һәм Конкурста җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

5.1. Конкурс материалларын бәяләү критерийлары

| № т/б | Бәяләү критерие | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | Эш чоры дәвамында укучыларның белем алуда ирешелгән казанышлары булу | 0-5 |
| 2 | Яшь педагогның мәгариф оешмасында сыналган үз методик системасы булуы | 0-5 |
| 3 | Төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык конкурсларында катнашу | 0-5 |
| 4 | Педагоглар һәм яшьләр өчен конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә, проектларда, ярышларда ирешелгән казанышлар булу | 0-5 |
| 5 | Казан шәһәренең яшь педагоглар ассоциациясендә эшләү | 0-5 |
| 6 | Төрле дәрәҗәдәге проектларда катнашу | 0-5 |
| 7 | Конференцияләрдә, түгәрәк өстәлләрдә, семинарларда һ. б. чыгышлар | 0-5 |
| 8 | Публикацияләр, авторлык эшләнмәләре, челтәр бергәлекләрендә эшләү | 0-5 |
| 9 | Шәхесне үстерү буенча квалификация күтәрү курслары, укыту, үзлегеңнән белем алу | 0-5 |

Һәр критерий биш баллы система буенча бәяләнә.

5.2. Жюри секретаре жюри утырышы узган көннән алып өч эш көне эчендә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасы буенча катнашучылар рейтингын төзи.

5.3. Конкурс нәтиҗәләре буенча 26.09.2024 кадәр 50 җиңүче билгеләнә.

Муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренә Конкурста җиңгән һәр кешегә 30 000 сум күләмендә субсидия бирелә.

5.4. Конкурс нәтиҗәләре буенча жюри әгъзалары тарафыннан имзаланган беркетмә рәсмиләштерелә, жюри рәисе яки аның урынбасары тарафыннан раслана. Конкурста җиңүчеләр һәм субсидияләр күләме турында мәгълүмат белән конкурс жюри беркетмәсе конкурс жюрие секретаре тарафыннан гаризалар рейтингы төзелгән көннән алып өч эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенең өстәмә битендә (www.obrazovanie.kzn.ru) урнаштырыла.

## VI. Субсидияне түләү, субсидиядән файдалануны контрольдә тоту, хисаплар тапшыру тәртибе

6.1. Конкурста җиңүчеләрнең исемлеген раслый торган жюри беркетмәсе Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе һәм субсидия алучы арасында Казан шәһәре Башкарма комитеты Финанс идарәсенең 2020 елның 29 декабрендәге 85 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль бюджет яисә автоном учреждениесенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан башка максатлардан субсидияләр бирү турында килешүләрнең (шартнамәләрнең) үрнәк формаларын раслау турында»гы боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү өчен нигез булып тора.

6.2. Яшь педагоглары Конкурста җиңүче дип танылган учреждение килешү төзү өчен Конкурс нәтиҗәләре турында Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенең өстәмә битендә (https://obrazovanie.kzn.ru/) мәгълүмат урнаштырганнан соң өч эш көненнән соңга калмыйча Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә әлеге нигезләмәгә 4 номерлы кушымтада билгеләнгән форма буенча гариза тапшыра һәм тапшырылган документларның тасвирламасын кушып, максатчан субсидия алу өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә түбәндәгеләрне тапшыра:

- әлеге нигезләмәнең 2.4, 6.7 пунктларында билгеләнгән максатларга бюджет акчаларын бирү кирәклеген нигезләүне, субсидия суммасының нигезләнгән хисабын, шул исәптән тәэмин итүчеләрнең (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәрен һәм (яисә) башка мәгъләматны керткән

аңлатма язуы;

- учреждениенең әлеге нигезләмәнең 6.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документлар.

6.3. Учреждение килешү төзү яисә субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айдан алдагы айның 1 нче көненә түбәндәге таләпкә туры килергә тиеш: учреждениене үзгәртеп оештыру яисә ябу буенча чаралар үткәрүгә, авария (гадәттән тыш) хәлен булдырмауга, авария (гадәттән тыш) хәле килеп чыккан очракта, аның нәтиҗәләрен бетерүгә һәм торгызу эшләрен башкаруга, законлы көченә кергән суд актлары, башкарма документлар буенча бурычны каплауга субсидия бирү очракларыннан кала, шулай ук федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенә караган югары башкарма органының норматив хокукый актлары, җирле администрациянең муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән башка очраклардан кала, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә учреждениенең түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән бурычлары булмавы, җирле бюджетка субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актларга нигезләнеп бирелгәннәрен кире кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы булмавы турында;.

6.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе:

а) гаризаны килеп ирешкән көнне терки;

б) гаризаны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә әлеге нигезләмәнең 6.2 пунктында күрсәтелгән документларны, аларның тулылыгын, алардагы мәгълүматның җитәрлек булуын һәм дөреслеген карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яисә бирүне кире кагу турында карар кабул итә.

Кирәкле барлык документларны тапшырмаган яисә аларны тиешенчә тутырмаган очракта, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, карап тикшерү вакыты тәмамланганчы ике эш көненнән дә соңга калмыйча, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен әлеге документларны кире кайтара.

Хәбәрнамә учреждениегә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Учреждение тарафыннан җитешсезлекләрне бетерү вакыты – әлеге хәбәрнамә теркәлгәннән соң, биш эш көненнән артык түгел. Документлар

теркәлгән көннән алып учреждение җитешсезлекләрне бетергәннән соң өч эш көне эчендә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе субсидия бирү турында яисә бирүне кире кагу турында карар кабул итә.

6.5. Субсидия алучыга субсидия бирүне кире кагу өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге нигезләмәнең 6.2 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләнү;

- Структур бүлекчәнең бюджет язмасында каралган бюджет йөкләмәләре лимитларын агымдагы финанс елында максатчан субсидияләр бирүгә тулысынча бүлү.

Субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, учреждениегә мондый карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә, субсидия бирүне кире кагу сәбәбен күрсәтеп, кире кагу турында хәбәрнамә җибәрелә.

Кире кагу турында хәбәрнамә учреждениегә структур бүлекчәгә электрон документ рәвешендә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә яисә Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына язма рәвештә килеп ирешкән гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча язма рәвештә җибәрелә.

Кире кагу өчен нигез булып торган җитешсезлекләр бетерелгән очракта, учреждение документларны кабат җибәрергә хокуклы.

6.6. Килешүдә субсидия бирүнең максатлары, төгәл, үлчәнелә торган һәм нәтиҗәләренә туры килергә тиеш булган субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре, матди һәм матди булмаган объектлар күрсәткечләрен һәм (яисә) тиешле программаларның, проектларның нәтиҗәләренә ирешкәндә алу планлаштырылган хезмәтләрне кертеп (мондый детальләштерү мөмкинлеге булганда), субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планы, субсидия күләме,субсидияне күчерү сроклары (графигы), хисап бирү вакыты, учреждение тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе үтәлмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм сроклары, килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән бюджет акчаларын алучы буларак гамәлгә куючы органга субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләренең алдан җиткерелгән лимитлары киметелгән

очракта, гамәлгә куючы орган карары буенча килешүне вакытыннан алда берьяклы тәртиптә, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә туктату өчен нигезләр: учреждениене үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш) яисә ябу, учреждениенең хокукый актта һәм (яисә) килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозуы, учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю.

6.7. Субсидия түбәндәге чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү өчен бирелә:

а) өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча Конкурста җиңүчене – яшь педагогны укыту;

б) Конкурста җиңүченең – яшь педагогның конференцияләрдә, укыту семинарларында (шул исәптән онлайн) катнашу;

в) Конкурс җиңүчесе – яшь педагог өчен үстерә торган мохит булдыру өчен методик әдәбият һәм җайланмалар сатып алу;

г) Конкурс җиңүчесе – яшь педагог өчен укытучының педагогик лабораториясе өчен материаллар (дидактик һәм күрсәтмә материаллар, укытыла торган предмет кысаларында программа тәэминаты, диагностик материаллар пакеты, лаборатор җиһазлар) алу.

6.8. Субсидия бирү нәтиҗәләре кимендә бер сатып алынган товар, эш, хезмәт күрсәтүдән гыйбарәт:

а) өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча Конкурста җиңүчене –яшь педагогны укыту;

б) Конкурста җиңүченең – яшь педагогның конференцияләрдә, укыту семинарларында (шул исәптән онлайн)катнашуы;

в) Конкурста җиңүче – яшь педагог өчен методик әдәбият һәм үстерү мохите булдыру өчен җайланмалар сатып алу;

г) Конкурста җиңүче – яшь педагог өчен укытучының педагогик лабораториясе өчен материаллар (дидактик һәм күрсәтмә материаллар, укытыла торган предмет кысаларында программа тәэминаты, диагностик материаллар пакеты, лаборатор җиһазлар) сатып алу.

6.9. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе субсидия алучының Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты территориаль бүлегендә ачылган исәп-хисап счетына килешү төзелгән көннән алып 10 эш көне эчендә субсидия күчерә.

6.10. Субсидия алучы Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә финанс белән тәэмин итүдә субсидия чыганак булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, килешүдә каралган форма һәм срокларда,

хисап тота торган елыннан соң килә торган елның 10 гыйнварыннан да соңга калмыйча, хисап бирә.

6.11. Хисап тота торган финанс елында файдаланылмаган максатчан субсидияләрнең калган өлеше Казан шәһәре бюджетына кайтарылырга тиешле.

6.12. Хисап тота торган елыннан соң килүче елның 15 гыйнварына кадәр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә килешүдә билгеләнгән срокларда кабул ителгән чыгым йөкләмәләре булмау сәбәпле Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиешле максатчан субсидияләрнең хисап финанс елында файдаланылмаган калган акчалары турында мәгълүмат җибәрә..

6.13. Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган, учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән керемнәрне максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен агымдагы финанс елында файдалану турындагы карар, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе белән килештереп, учреждение тарафыннан кабул ителә

Максатчан субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган, учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалардан агымдагы финанс елында файдалану турында карар кабул итү өчен учреждениеләр Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә учреждениенең учреждениеләр тарафыннан элек бирелгән түләүләрне кире кайтарудан алынган акча финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган үтәлмәгән йөкләмәләре булуы турында мәгълүматны, шулай ук учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм күләмен раслый торган документларны (документлар күчермәләрен), акча килеп ирешкәннән соң, өч эш көне эчендә тапшыра

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсеәлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат килеп ирешкәннән соң, 10 эш көне эчендә килештерү/ килештермәү турында карар кабул итә

6.14. Россия Федерациясе законнары нигезендә субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерү, шул исәптән субсидияләр биргәндә билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, шулай ук муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла

6.15. Тикшерүләр нәтиҗәсе буенча учреждениенең максатчан субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, максатчан субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, шулай ук учреждение әлеге тәртипнең III бүлегендә билгеләнгән тәртиптә максатчан субсидиядән файдалану турында хисаплар тапшырмаган очракта, максатчан субсидия Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына кире кайтарылырга тиеш

6.16. Максатчан субсидияне яисә аның бер өлешен кайтару турында таләп аны алган көннән алып 30 (утыз) календарь көн эчендә учреждение тарафыннан үтәлергә тиеш.

Субсидияне кире кайтару турындагы таләп билгеләнгән вакытта үтәлмәгән очракта, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе аны Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтүне тәэмин итә

6.17. Учреждение җитәкчесе килешүдә каралган шартлар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә максатчан субсидияләрдән файдаланган өчен җавап тота.

«Казан шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма
комитетының Мәгариф идарәсе»
муниципаль казна учреждениесе
карамагындагы муниципаль
автоном һәм бюджет гомуми
белем бирү учреждениеләренең
яшь педагогларын укытуга һәм
һөнәри үстерүгә конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(форма)

**«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурсында катнашуга гариза**

| **Фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Эш урыны** | **Вазифа** | **Телефон номеры, электрон почта адресы** |
|---|---|---|---|
| | | | |

«Казан шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма
комитетының Мәгариф идарәсе»
муниципаль казна учреждениесе
карамагындагы муниципаль
автоном һәм бюджет гомуми
белем бирү учреждениеләренең
яшь педагогларын укытуга һәм
һөнәри үстерүгә конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(форма)

**«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурсында катнашучының портфолиосы**

| | | |
|---|---|---|
| Фамилиясе,исеме, атасының исеме, туу датасы | | |
| Эш урыны, вазифа, эш стажы | | |
| **№ т/б** | **Күрсәткеч** | **Тасвирлама** |
| 1 | Эш чоры дәвамында укучыларның белем алуда педагогның ирешелгән казанышлары | |
| 2 | Яшь педагогның мәгариф оешмасында сыналган үз методик системасы булуы | |
| 3 | Төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык конкурсларында катнашу | |
| 4 | Педагоглар һәм яшьләр өчен конкурсларда, олимпиадаларда, конференцияләрдә, проектларда, ярышларда ирешелгән казанышлар булу | |
| 5 | Казан шәһәренең яшь педагоглар ассоциациясендә эшләү | |
| 6 | Төрле дәрәҗәдәге проектларда, шул исәптән яңа белем бирү программалары, дәреслекләр, социаль әһәмиятле инициативалар, педагогик бергәлекләр чараларында катнашу, студентларның | |

| | | |
|---|---|---|
| | педпрактикасы белән җитәкчелек итү | |
| 7 | Конференцияләрдә, түгәрәк өстәлләрдә, семинарларда һ. б. чыгышлар | |
| 8 | Публикацияләр, авторлык эшләнмәләре, челтәр бергәлекләрендә эшләү | |
| 9 | Шәхесне үстерү буенча квалификация күтәрү курслары, укыту, үзлегеңнән белем алу | |

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә 3 номерлы кушымта (форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ________________________________________

__________________________________________________________________________,
*(катнашучының/катнашучының законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

паспорт ____________________________________________________________,

______________________________________________________,
*(сериясе, номеры) (кайчан бирелгән һәм документны биргән органның атамасы)*

теркәлү адресы: ________________________________________________________

__________________________________________________________________________,

фактта яшәү урыны: ___________________________________________,

Идарә карамагындагы мәгариф оешмаларының яшь педагогларына укытуга субсидияләр бирүгә конкурсында катнашуга бәйле рәвештә

__________________________________________________________________________
*конкурста катнашучы эшли торган оешманың атамасы*

һәм минем тарафтан бирелгән, Идарә карамагындагы мәгариф оешмаларының яшь педагогларына укытуга субсидияләр бирүгә конкурсында катнашу белән бәйле рәвештә, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә, Идарә карамагындагы мәгариф оешмаларының яшь педагогларына укытуга субсидияләр бирүгә конкурсында катнашу максатыннан, 420111, Казан шәһәре, Зур Кызыл ур., 1 йорт адресы буенча урнашкан «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (алга таба – Идарә), шул исәптән жюри һәм экспертларга, җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңартуны, үзгәртүне), алуны, файдалануны, тапшыруны (бирүне, файдалану өчен рөхсәтне), шәхси үзенчәлекләрен юк итүне, тыюны, бетерүне, юкка чыгаруны кертеп, автоматлаштырылган режимда, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси

мәгълүматларны, шул исәптән шәхси мәгълүматларның махсус категориясен, эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

.

Әлеге ризалык эшкәртүгә кагыла торган шәхси белешмәләргә конкурста катнашуга гаризада һәм минем 2024 елда конкурста катнашуыма кагылышлы башка документларда бирелгән белешмәләр керә.

Әлеге ризалык 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә аңа кул куелган көннән алып язма рәвештә кайтартып алынган көнгә кадәр гамәлдә була.

Мин Идарәгә тапшырган барлык мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Минем шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта ун көн эчендә Идарәгә хәбәр итәргә сүз бирәм.

Мин, мондый ризалык биреп, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә эш итәүемне раслыйм.

Мин Идарә шәхси мәгълүматларны автоматлаштырылмаган һәм автоматлаштырылган эшкәртү ысулы белән эшкәртәчәге турында хәбәр ителдем.

«______» ___________ 20____ ел. ________________ /________________/

(имза) (фамилия һәм инициаллар)

«Казан шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма
комитетының Мәгариф идарәсе»
муниципаль казна учреждениесе
карамагындагы муниципаль
автоном һәм бюджет гомуми
белем бирү учреждениеләренең
яшь педагогларын укытуга һәм
һөнәри үстерүгә конкурсын
үткәрү турында нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(форма)

Казан шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләренә яшь педагогларны укытуга һәм һөнәри үстерүгә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр алуга

ГАРИЗА

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры | |
| 3 | Төп дәүләт теркәве номеры | |
| 4 | Юридик адрес | |
| 5 | Телефон | |
| 6 | Электрон почта адресы | |
| 7 | Җитәкче | |
| 8 | Субсидия күләме, сум | |
| 9 | Субсидияне күчерү өчен реквизитлар | |
| 10 | Субсидия алу мөмкинлеген бирә торган дөрес булмаган белешмәләр тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык каралган булуы турында миңа әлеге гариза белән хәбәр ителде________________ (имза) | |
| 11 | Учреждениенең «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәнең 6.3 пунктында каралган таләпләргә туры килүен раслыйм | |
| 12 | Субсидия бирү шартлары белән таныштым һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе карамагындагы муниципаль автоном һәм бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренең яшь педагогларын укытуга һәм һөнәри үстерүгә конкурс үткәрү турындагы Нигезләмә нигезендә кирәкле документларны исемлек нигезендә тапшырам | |

Директор ___________________________________________

(имза, фамилия һәм инициаллар)

Гариза тапшыру датасы: : 20_______ елның «_______» ______________________